ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.04.2023 Балык Бистәсе штп. № 124пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль берәмлекләр Башкарма комитетларының үзәкләштерелгән бухгалтерлык җитәкчеләре һәм белгечләре, баш бухгалтерлар һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәт вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын түләүне оештыру һәм шартлары турында» 27.05.2019 №181пи карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының «Шәһәр һәм авыл җирлекләрендә үзәкләштерелгән бухгалтерияләр һәм бухгалтерлар җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәт хакы турында» гы 09.08.2022 №03-16/5605 хаты нигезендә карар бирәм:

1Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль берәмлекләр Башкарма комитетларының үзәкләштерелгән бухгалтерлык җитәкчеләре һәм белгечләре, баш бухгалтерлар һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәт вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын түләүне оештыру һәм шартлары турында» 27.05.2019 №181пи карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1 Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының финанс-хуҗалык бүлекләре җитәкчеләре һәм белгечләренең хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында Нигезләмәнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының финанс-хуҗалык бүлекләре җитәкчеләренең һәм белгечләренең вазыйфаи хезмәт хаклары түбәндәге күләмдә билгеләнә:

| Җитәкчеләр һәм белгечләр вазифалары | Вазифаи хезмәт хакы, сум | |
|---|---|---|
| | Муниципаль учреждение булган үзәкләштерелгән | Башкарма комитетның (җирле үзидарәнең башка органы) структур |

| | бухгалтерияләр өчен | бүлекчәсе (бүлеге)булган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен |
|---|---|---|
| Муниципаль учреждение җитәкчесе | 27 700 | |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе урынбасары | 25 500 | |
| Башкарма комитетның структур бүлекчәсе җитәкчесе (баш бухгалтер) | | 25 500 |
| Бүлек башлыгы | 21 700 | 21 700 |
| Әйдәүче бухгалтер | 19 300 | 19 300 |
| Бухгалтер | 18 000 | 18 000 |

Муниципаль учреждение булган үзәкләштерелгән бухгалтериянең штат расписаниесенә җитәкче урынбасары вазифасын кертү шарты булып структурада штат саны 5 берәмлектән ким булмаган 3 бүлек булуы тора.

Үзәкләштерелгән бухгалтерлык бүлекләренең штат саны 5 берәмлектән ким булмаска тиеш.»;

1.2 Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль берәмлекләре Башкарма комитетларының баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәт вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын түләүне оештыру һәм шартлары турында Нигезләмәнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Бухгалтерларның вазифа хезмәт хакы түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазифа | Халык саны белән муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары | |
|---|---|---|
| | 3,5 мең кешегә кадәр | 3,5 мең кешедән артык |
| Баш бухгалтер | 19 700 сум | 21 000 сум |
| Бухгалтер | | 18 500 сум |

Муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетларының штат расписаниесенә бухгалтер вазифасын кертү шарты булып муниципаль берәмлек халкының саны 3,5 меңнән артык кеше булу тора.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм аның гамәле 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе И.М. Ногмановага йөкләргә (килешү буенча).

Җитәкче Д.А. Сатдинов